# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«16» 04 2020 ел Яр Чаллы № 1422

Башкарма комитетның 2018 елның 18 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә контроль буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 4328 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 269.2 статьясына, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясына, 2009 елның 27 декабрендәге 449-ФЗ номерлы Федераль законга таянып

## КАРАР БИРӘ:

1. Башкарма комитетның 2018 елның 18 сентябрендәге 4328 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә контроль буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибе»нә, түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

6 пунктны: «Финанс-бюджет өлкәсендә контроль буенча эшчәнлекне тормышка ашырганда, Палата түбәндәгеләрне контрольдә тоту буенча вәкаләтләрне башкара:

Россия Федерациясе бюджет законнары һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка норматив хокукый актлар үтәлешен;

муниципаль программаларны гамәлгә ашыру турында, шул исәптән муниципаль биремнәр үтәлеше турында хисапларның тулылыгын һәм дөреслеген;

контракт системасы турында Федераль законның 18 статьясында каралган сатып алуларны нигезләүгә карата таләпләрне һәм сатып алуларның нигезлелеген үтәүне;

контракт системасы турында Федераль законның 19 статьясында каралган сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру кагыйдәләрен үтәүне;

контрактның башлангыч (максималь) бәясен, бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән төзелә торган контрактның бәясен нигезләүне;

китерелгән товарның, башкарылган эшнең (нәтиҗәсенең) яки күрсәтелгән хезмәтнең контракт шартларына туры килүен».

7 пунктка өстәргә: «Контроль объектлары булып тора:

и) «максатчан билгеләнеше булган бюджетара субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар, бюджет кредитлары бирелгән гавами-хокукый берәмлекнең финанс органы (җирле администрация)»;

е абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«юридик затлар (муниципаль) учреждениеләрдән, муниципаль унитар предприятиеләрдән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм устав (җыелма) капиталларында Тукай муниципаль районы катнашкан җәмгыятьләр, шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр өлеше (кертеме) булган коммерция оешмалары), хосусый эшмәкәрләр, физик затлар, алар:

тиешле бюджеттан һәм (яисә) муниципаль контрактлардан акча бирү турындагы шартнамәләр (килешүләр) нигезендә тиешле бюджеттан акча, муниципаль гарантияләр белән тәэмин ителгән кредитлар алучы юридик һәм физик затлар, шәхси эшмәкәрләр;

федераль законнар нигезендә Федераль казначылыкта, муниципаль берәмлекнең финанс органында шәхси счетлар ачылган, тиешле бюджеттан һәм (яки) муниципаль контрактлардан акча бирү турындагы шартнамәләрне (килешүләрне) үтәү максатында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча башкаручылар (тәэмин итүчеләр, подрядчылар)».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районы сайтында (tukay.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны финанс-бюджет палатасы рәисе Л.Н. Хуҗагалиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов